КОМИТЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ПО ОХРАНЕ ОБЪЕКТОВ
КУЛЬТУРНОГО НАСЛЕДИЯ

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ МӘДӘНИ
МИРАС ОБЪЕКТЛАРЫН
САКЛАУ КОМИТЕТЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

02.03.2023 г. Казань № 64-П

Татарстан Республикасы Казан шәһәре
муниципаль берәмлеге территориясендә урнашкан
«Кадыш җирлеге» ачыкланган мәдәни мирас
объектын ачыкланган мәдәни мирас исемлегенә
кертү, территориясенең чикләрен һәм аннан
файдалану режимын раслау турында

«Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни һәйкәлләре) турында» 2002 елның 25 июнендәге 73-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында мәдәни мирас объектлары турында» 2005 елның 1 апрелендәге 60-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 12 июлендәге 565 номерлы «Мәдәни мирас объектларын саклау буенча Татарстан Республикасы комитеты мәсьәләләре» карары нигезендә б о е р а м:

1. Бу боерыкка 1 кушымта нигезендә Татарстан Республикасы Казан шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә урнашкан «Кадыш җирлеге» ачыкланган мәдәни мирас объектын ачыкланган мәдәни мирас исемлегенә кертергә (бастырылырга тиеш түгел).

2. Бу боерыкка 2 кушымта нигезендә Татарстан Республикасы Казан шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә урнашкан «Кадыш җирлеге» ачыкланган мәдәни мирас объектының чикләрен расларга (бастырылырга тиеш түгел).

3. Бу боерыкка 3 кушымта нигезендә Татарстан Республикасы Казан шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә урнашкан «Кадыш җирлеге» ачыкланган (археологик) мәдәни мирас объектыннан файдалану режимын расларга.

4. Мәдәни мирас объектларын исәпкә алу һәм шәһәр төзелеше эшчәнлеге бүлегенә ачыкланган мәдәни мирас объекты территориясе чикләре турында белешмәләрне күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрына кертүне тәэмин итәргә.

5. Боерыкның үтәлешен тикшереп торуны Комитет рәисе урынбасары М.М. Вәлиуллинга йөкләргә.

Рәис И.Н. Гущин

Татарстан
Республикасы мәдәни
мирас объектларын
саклау комитетының
2023 елның 2
мартындагы 64-П
боерыгына 3
кушымта

Татарстан Республикасы Казан шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә урнашкан «Кадыш җирлеге» ачыкланган (археологик) мәдәни мирас объекты территориясе чикләреннән файдалану режимы турында

Чикләрендә ачыкланган археологик мирас объекты урнашкан җир кишәрлекләреннән файдалануның аерым режимы «Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарих һәм мәдәният һәйкәлләре) турында» 2002 елның 25 июнендәге 73-ФЗ номерлы Федераль законда (алга таба - 73-ФЗ номерлы Федераль закон), ачыкланган археологик мирас объектының сакланышын тәэмин итү шартларында урманнардан файдалану һәм башка эшләр буенча 73-ФЗ номерлы Федераль законның 30 статьясында күрсәтелгән җир, төзелеш, мелиорация, хуҗалык эшләрен башкару, шулай ук гражданнарның күрсәтелгән объектка керүен тәэмин итү шартларында археологик кыр эшләрен башкару мөмкинлеген күздә тота.

Археологик мирас объекты чикләрендә урнашкан су объектын яисә аның өлешен куллануның аерым режимы ачыкланган археологик мирас объектының сакланышын тәэмин итү, шулай ук 73-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән тәртиптә гражданнарның әлеге объектка керүен һәм археологик кыр эшләрен уздыруны тәэмин итү шартларында Россия Федерациясе Су кодексында билгеләнгән эшләрне башкару мөмкинлеген күздә тота.